**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25» 12 2019 ел Яр Чаллы № 5611

Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясен төзү турында

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 19 ноябрендәге 1006 номерлы карары нигезендә

**К А Р А Р  Б И Р Ә:**

1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясен төзергә.
2. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25.12. 5611 номерлы карарына кушымта

**Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә**

1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе (алга таба – комиссия) Балалар һәм яшьләрнең ялы, аларны сәламәтләндерү программасын гамәлгә ашыру максатында оештырылды һәм район Башкарма комитетының эшче органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары:

- 2020 елгы сәламәтләндерү кампаниясе чорында район Башкарма комитеты бүлекләре, шулай ук район территориясендә урнашкан дәүләт органнары, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү;

- район Башкарма комитеты бүлекләре, шулай ук район территориясендә урнашкан дәүләт органнарының, предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең балалар һәм яшьләрнең ялын әзерләү һәм оештыру буенча эшчәнлеген анализлау, комиссия утырышларында аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

- балалар һәм яшьләрнең ялын финанслау һәм оештыру мәсьәләләрен карау.

4. Комиссия хокуклы:

- Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы район Башкарма комитеты бүлекләреннән, дәүләт органнарыннан, район предприятиеләреннән, оешмаларыннан, учреждениеләреннән үз компетенциясенә караган документлар, белешмәләр, материаллар соратып алырга;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча оештыру документларының үтәлешен контрольдә тотарга.

5. Комиссия составы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. Комиссияне рәис җитәкли, аның бер урынбасары була. Рәис комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышларны алып бара. Комиссиянең эш планын раслый. Комиссия рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия составына шулай ук комиссия секретаре керә.

Комиссия секретаре комиссия утырышларын әзерләү эшен оештыруны һәм комиссия утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешенә мониторингны гамәлгә ашыра. Секретарь комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча комиссия рәисе һәм аның урынбасары күрсәтмәләрен үти.

8. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләсе буенча кабул ителгән комиссия карарлары Башкарма комитетның барлык бүлекләре, дәүләт органнары, район оешмалары тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

9. Комиссия үз эшчәнлеген утырышларында кабул ителгән һәм комиссия рәисе тарафыннан расланган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

10. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Комиссия рәисе утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен билгели.

11. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

12. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, алар комиссия рәисе тарафыннан имзалана. Тавышлар саны тигез булганда, комиссия рәисе яисә утырышта рәислек итүче комиссия рәисе урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.